Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге
“Татарстан” совхозы поселогы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«18» ноябрь, 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә “Татарстан” совхозы поселогы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1.«2023 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге “Татарстан” совхозы поселогы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:
- "Татарстан" совхозы торак пунктында коймалар әзерләү һәм урнаштыру;
-"Татарстан" совхозы торак пунктында яктырткычлар сатып алу, урам яктырткычларын монтажлау һәм урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында юлларны ремонтлау;
- "Татарстан"торак пунктында газоннарны яшелләндерү һәм урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- "Татарстан" совхозы торак пунктында территорияне чистарту һәм төзекләндерү (махсус техника хезмәте, грунт ташу);
- зират территорияләрен төзекләндерү һәм "Татарстан"совхозы торак пунктында инвентарь алу
-Татарстан торак пунктында суүткәргечне ремонтлау
-Татарстан торак пунктында газ компенсаторын реконструкцияләү
-газон чапкычлар сатып алу

2.РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын Князево авыл җирлеге территориясендә теркәлгән взнослардан азат итәргә.

3. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге “Татарстан” совхозы поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге “Татарстан” совхозы поселогы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.М.Камалов